СОВЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.16, д.Пойкино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Октябрь ур., 16 нче йорт, Пойкино авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-19; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                                        Карар

“19 ” февраль 2020 ел                                        № 2-50

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советының 2017 елның 15 маендагы 4-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында «Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 9 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советының 2017 елның 15 маендагы 4-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3.2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль норматив хокукый актлар кабул ителгән (бастырып чыгарылган) көннән алып 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкил тарафыннан вәкаләтле органга җибәрелә.

Муниципаль норматив хокукый акт Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән алып 10

эш көне эчендә  рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителү) очракта аны вәкаләтле органга җибәрү таләп ителми.»;

1.2. 3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.4 пункты белән тулыландырырга:

«««3.4. Муниципаль норматив хокукый акт белән бер үк вакытта Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкил муниципаль норматив хокукый актның барлык рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) халыкка чыганаклары һәм даталары турында белешмәләрне җибәрә.

Муниципаль норматив хокукый акт Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2017 елның 15 маенда кабул ителгән № 4-21 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәнең  3.2 пунктчасының икенче абзацы нигезендә вәкаләтле органга җибәрелмәгән очракта, муниципаль норматив хокукый акт «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка игълан ителгән) алып  10 эш көне эчендә,  муниципаль норматив хокукый актларның барлык башка рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) чыганаклары һәм даталары турындагы  белешмәләр күрсәтелгән вакыт эчендә әлеге порталга урнаштырылмаса, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкил тарафыннан мондый белешмәләр дә җибәрелә.

Муниципаль норматив хокукый акт Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Keләүш авыл җирлеге советының 2017 елның 15 маенда кабул ителгән № 4-21 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәнең 3.2 пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң  рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) очракта,  рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) чыганаклары һәм даталары турында белешмәләр, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" (pravo.tatarstan.ru)  басылып  чыгу (халыкка игълан ителү) турындагы белешмәләрдән тыш, аның рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга җибәрелә.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле органга рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле орган запросы буенча 15 көн эчендә бастырып чыгару чыганагы булган

басма чаралардагы публикацияләренең үзе раслаган күчермәләрен вәкаләтле органга җибәрәләр.»;

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru). урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Келәүш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Б.В.Иванов/